Гадел Кутуй иҗаты. “Тапшырылмаган хатлар”.

Тормыш юлы

Гадел Кутуев 1903 елның 28 ноябрендә Сарытау губернасының Кузнец көязе Татар Кынадысы авылында мул тормышлы крестьян гаиләсендә туа. Башлангыч белемне туган авылындагы мәктәптә ала.

1912 елда әтисе Нурмөхәммәт, игенчелек эшен ташлап, гаиләсе белән Самар губернасы Алексеевка дигән авылга күченә һәм бертуган Кутуевларның күн заводында эшли башлый. Гадел шунда урыс мәктәбендә укуын дәвам иттерә.

1917 елда бертуган Кутуевлар 4 гаилә бергә Самар шәһәренә күчеп киләләр. Булачак язучының белем алуы һәм әдәби сәләтенең ачылып китүе өчен монда шартлар тагын да уңайлана төшә.

Мәктәптә укуы белән бергә ул шәһәрдәге мәдәни клубларның берсендә рус язучысы Александр Неверов оештырган әдәби түгәрәккә йөри, рус телендә өйрәнчек беренче шигырьләрен яза, ныклап торып шул чордагы яна рус поэзиясе, аерым алганда, Владимир Маяковский иҗаты белән якыннан таныша.

1920 елда унҗиде яшьлек Гадел укуын дәвам итү һәм татар әдәбиятына якынрак булыр өчен, Казанга килә һәм политехника институтының химия факультетына керә.

Ләкин ике курсны тәмамлагач, төгәл фәннәргә күңеле ятмыйча, институтта укуын ташлый һәм Казан Татар-башкорт хәрби мәктәбенә әдәбият укытучысы булып эшкә керә. Бу чорда аның иҗат эшчәнлеге активлаша.

1925 елда Гадел Кутуй Казан шәрекъ педагогия институтының урыс теле һәм әдәбияты бүлегенә керә.

1929 елда институтны тәмамлап чыккач, 1930-еллар дәвамында Казан коммуналь төзелеш инженерлары институтында фәнни сәркатип, мәктәпләрдә һәм Казан авиация теникумында әдәбият укытучысы булып эшли.

1942 елның июнендә Г.Кутуй фронтка китә һәм башта Сталинградны саклаучы Дон фронтының авыр гвардия миномет бригадасы сәяси бүлегендә хезмәт итә, Идел буенда Сталинград сугышында катнашканы өчен, «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә

Иҗат юлы

- *Гадел Кутуйның иҗат эше 1920-еллар башында активлашып китә. 1923 елда «Безнең юл» журналының 4-5 саннарынла «Яшь футурист шагыйрь» дигән исем белән, аның бер төркем шигырьләре басыла.*
- *1924 елда исә «Көннәр йөгергәндә» исемле иң беренче җыентыгы дөнья күрә. Андагы футуристик шигырьләр Владимир Маяковский һәм башка урыс шагыйрьләренең шигырьләренә тышкы яктан охшатып язылган булалар. Гәрчә аларда аерым уңышлы чагыштырулар, образлы тәгъбирләр булса да, тулаем аңлаешсыз һәм бик тә сәер яңгыраган бу әсәрләр шул заман әдәби тәнкыйтьтенең кискен каршылыган очрый*

- *«Җидегәнчеләр» эше буенча гаепләнгә күрә, Кутуй 1930-елларда әдәби эшне ташлап, бары мөгаллимлек белән генә шөгыльләнергә мәҗбүр була. 1935 елда гына ул беренче тапкыр «Совет әдәбияты» журналында нәшер ителә, аның «Тапшырылмаган хатлар» повесте 9-12 саннарда басылалар.*
- *Кутуйның сугыш алды чоры прозасында исә тормышны артык бизәп, аның бары яхшы якларын гына күрсәтү чагыла. Бу чордагы әсәрләрдән, мәсәлән, «Солтанның бер көне» (1938) исемле озын хикәясендә ул гаилә корырга йөрүче яшь укытучы егетнең көндәлек тормышы, күңел ачулары турында сөйләп, тормышның гүзәллегенә дан җырлый. Шундый рухта «Вөҗдан газабы» (1939), «Нишләргә?» (1940), «Илһам» (1941) хикәяләре, «Шатлык җыры» пьесасы (1935) һәм «Талантлар ватаны» поэмасы (1937) да язылганнар.*

- *Бөек Ватан сугышының беренче елында Гадел Кутуй патриотик әсәрләр: «Озату җыры», «Партизанка», «Батыр каберендә», «Яңа ел бүләге» һ.б. Шигырьләрен «Рәссам», «Хәнҗәр» кебек хикәяләрен, «Патриот Тукай», «Партизаннар», «Җиңү хәбәрчесе» кебек зур күләмле мәкаләләрен иҗат итә. Сталинград сугышы катнашканнан соң ул «Без – сталинградчылар» нәсерен яза, 1945 елда исә тагын бер патриотик хисләр белән сугарылган «Сагыну» нәсерен иҗат итә. 1944 елда бик кыска иҗади ялга Казанга кайткач, «Рөстәм мажаралары» исемле фантастик-хыялый повестен иҗат итә. Ул аны улы Рөстәмгә багышлап яза .*
- *Гадел Кутуйның иҗаты тикшеренүчеләр тарафыннан киң өйрәнелә. Шулай ук татар әдәбияты дәреслекләренә дә аның тормыш юлы хакында мәгълүмат һәм сайланма шигырьләре, нәсерләре кертелә.*

"Тапшырылмаган
хатлар"

- *Повестьның автор төзәткән нөсхәсе.*



~~Хатнь җунда өзем.~~

Iskəndər!

Kyrgə bylmədə Vəli utьrə. Jaza almьjm, qullarьm qaltьrьj: Vəli:

- Irtəgə kitəm, qaliə. Lakin kitəse kilmi. Iələştəm. Bulaj da kitəm. "Kirlə irəq" bulmamnьq, səsəsən tizrək beləsəm kilə. Juqsa, taqь da jartь ajqa qaltьrqa məmkin ide. Qalsam, bətenləj kitə alsam, di, qurqaq. Səmne acьqьz?- di.

Min, "xəzer" dip ikəncə bylməgə kərəm həm җuҗь syzlərnə jazam. Bolaj qьna səjləp min əqər sarьsət aqlata almam. Cənki yzəmnə bik nacar xis itəm. [illegible] da siqa jazьlqan xatnь min Vəligə birəgə buldьm. Uqьqьz da teləsə nicək aqlasьn. Xəzer janьna cьqam da:

- Mə, dustьm, җunь uqь cьq. Bu minəm tormьşьm. Җunnan barьn da aqlarsьq,- dim.

Bette. Xuҗ, Iskəndər!

Qəderle uqucьm!

Bibl jaz kənə miqa bər səmiədə qunaqta bulьrqa turь kilde. Bu səmiə yzənəq җatlьqь, səxətlələgə bələn minə bik qьzьqtьrdь. Bul xətle tatu torqan səmiənə bik birək ocratьrqa turь kilə. Bərsə ~~yzəncə~~ yaqtucь, zur uҗlərə əcən ordən bələn byləkləngən, ikəncəsə doktor-jaqa qьna ~~sacəstrujuҗcilər~~ tabsirujuҗcilər gruppasьna kergən. Ike balalarь bar. Min alarqa bər kic majьn bərəp jeri saqladьm. Həm soqqь barularьnь bərsəndə:

- Sez, bik jaxqь torasьz. Bərəncə tanьşuqьz nicək buldь? Nicək bər bərləşəng tuptьqьz? Səjlərgə jarьjmь,- dip soradьm.

Jaqa duslarьm miqa əlegə xatnь cьqarь birdələrəm

- Sez jazucь bit, fajdalanьrqa məmkin- didel ər.

Min xatnь uqьp cьqu bələn familiələrnə həm rajon avьl isəmnərən almaqtьrьp duslarьmnьq rəxsətə bələn mətsuqatqa cьqarьrqa ujladьm.

G. Qutuj

"Тапшырылмаган хатлар"

Беренче хат- мәхәббәт тарихы

- Яшьләрнең танышулары, мәхәббәтләре;
- Галиянең үткәне белән бүгенгесе контраст буларак бирелә;
- әледән-әле киләчәк тормыш мактала;
- язучы мәхәббәт, гаилә, ир белән хатын мөнәсәбәтләре турында өстәмә вакыйгалар, лирик чигенешләр бирә.

Икенче хат- гаилә тарихы

- Искәндәр белән Галиянең өйләнешүе, гаиләдәге беренче каршылыклар;
- бәхетле, ныклы гаилә турында автор уйланулары;
- Искәндәр Галияне ташлап китә, ә Галия ике баласы белән Әдрәс авылына күчә.

"Тапшырылмаган хатлар"

Өченче хат - хезмәт юлы тарихы

- Галиянең Әдрәстәге тормышы;
- аның табиб буларак танылуы;
- шәхси сыйфатларының тулырак ачылуы;
- Галия – Вәли сызыгы килеп керә.

Дүртенче хат – бәхеткә омтылу тарихы

- Галиянең Вәли белән очрашуы;
- Хатларны Вәлигә бирүе

Тапшырылмаган хатлар” әсәренең аерым китап булып басылган кырыктан артык басмасы бар.

Җир шарында иң күп таралган дүрт татар китабының беренчесе – ул.

Әсәр рус, башкорт, казах, кыргыз, мари, тува, гарәп, монгол, вьетнам, чех, үзбәк, каракалпак, чуваш, инглиз, француз, албан, корея, кытай һ. б. телләргә тәрҗемә ителә.

Мин "Тапшырылмаган хатлар"да безнең чорның татар хатыны турында, аның бай һәм матур эчке дөньясы турында, сәләтлелеге турында сөйләргә теләдем.

Г.Кутуй